ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл жирлеге башлыгы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

Глава Старотатарско-Адамского сельского поселения Аксубаевского муниципального района

423055 Республика Татарстан Аксубаевский район с. Старый Татарский Адам, ул. Центральная дом 20
Тел. (8-84344-4-35-84) ОГРН 1021605359610,
ОКПО 27839564, ИНН/КПП 1603000965/160301001
E-mail: *Stadam.Aks@tatar.ru*

---

КАРАР

17 ноябре 2023 ел ел. № 7

Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге
Тахтала авылы
гражданнарының үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану
мәсьәләсе буенча гражданнар
җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 ел, 28 июль, 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2023 елның 28 ноябрендә 13.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы Аксубай районы Тахтала авылы Мәктәп урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасы янында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлегенең Тахтала авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

Аксубай муниципаль районы Иске Татар Әдәмсуы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлары, Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларны (хәрби хезмәткәрләрне, контракт буенча хезмәткәрләрне, волонтерларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергәләп яшәүче ата-аналар, ир белән хатыннар, балигъ булган балалар)түләүдән азат итүдән тыш, 500 сум күләмендә 2024 елда үзара салым кертү һәм алдагы эшләрне

башкару буенча әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме?:

1. Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;
Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау һәм тоту (Тахтала торак пунктында вак таш сатып алу, вак таш салу буенча эшләрне башкару; юлларны кышкы тоту (килешү буенча түләү).

2. Торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үткәрүне тәэмин итү:
беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү (янгын сүндерү машинасын тоту: ягулык-майлау материаллары сатып алу).
3. Ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын тоту:
- ремонт, коймалар төзү, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү(Тахтала авылы зиратында хозблок өчен материаллар сатып алу)

4. Күрсәтелгән Кагыйдәләргә ярашлы рәвештә торак пункт территориясен төзекләндерүне оештыру:
- урамнарны яктырту җайланмасы(торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен килешү буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, Тахтала авылы урамнарында энергияне саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру)
яр буе зоналарын һәм сулыкларны чистарту (Тахтала авылы буасын ремонтлау (килешү буенча түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://Aksubayevo.tatarstan.ruһәмхокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга:http://pravo.tatarstan.ru/

Аксубай муниципаль районы
Иске Татар Әдәмсуы авыл
җирлеге башлыгы: Э. М. Хөснуллина